Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының
бишенче чакырылышының дүртенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

4 декабрь, 2025 ел № 24

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2016 елның 19 апрелендәге 38 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары белән (Питрәч муниципаль районы Советының 2017 елның 13 июлендәге 101 номерлы, 2017 елның 14 сентябрендәге 111 номерлы, 2018 елның 26 апрелендәге 141 номерлы, 2018 елнын 24 октябрендәге 164 номерлы, 2019 елның 28 февралендәге 184 номерлы, 2019 елның 25 июлендәге 212 номерлы, 2020 елның 26 мартындагы 249 номерлы, 2020 елнын 14 маендагы 263 номерлы, 2021 елның 22 мартындагы 251 номерлы, 2021 елның 23 маендагы 253 номерлы, 2021 елның 22 августындагы 384 елның 22 декабрендәге 324 номерлы, 2021 елның 22 маендагы 254 номерлы, 2021 елның 22 августындагы 384 елнын 22 февралендәге 324 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре» 2.3 өлешенең 2.3.1 пунктында:

- 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) һөнәри белем дәрәжәсенә: авыл җирлекләренең җирле үзидарә органнарында вазыйфалардан тыш, вазыйфаларның югары, төп һәм әйдәүче төркемнәре өчен; авыл җирлекләре җирле үзидарә органнарында вазыйфаларның югары, баш һәм әйдәүче төркемнәре өчен, шулай ук вазыйфаларның өлкән һәм кече төркемнәре өчен югары белем яисә урта һөнәри белем булу;»

- 2 пунктчада беренче, икенче һәм өченче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль хезмәт стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең югары вазыйфалары буенча - кимендә бер ел муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике ел эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча - муниципаль хезмәт стажы яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча кимендә бер ел эш стажы.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы Р.Ә. Сөләйманов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПЕСТРЕЧИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ПИТРӘЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ИНН 1633605407